ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 607 2017 елның 29 сентябре

# Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында 2017 елның 1 сентябреннән укучыларның туклануын оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларының азык-төлек иминлеген тәэмин итү һәм туклануын оештыру максатларында, карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында 2017 елның 1 сентябреннән укучыларының туклануын оештыру турында» карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарның 2, 4, 5, 5.1, 5.2, 6 пунктлары, карар белән расланган Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдәге балаларны тукландыруны оештыру тәртибе турында Нигезләмәнең 2, 3 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.

Карарны түбәндәге эчтәлектә 6.1 пункт белән тулыландырырга:

«6.1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында туклану бәясен расларга (2 нче кушымта)».

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә (В.Н. Матюшин) Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы социаль якланмаган гаиләләрдәге балаларга күрсәтелгән гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар бирү турында социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы аша мәгълүмат тапшыруны тәэмин итәргә.

Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы социаль якланмаган гаиләләрдәге балаларга бирелгән гарантияләр, хокуклар һәм ташламалар турындагы мәгълүмат социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы аша алынырга мөмкин.

3. Әлеге карар 2017 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә үз көчен юнәлдерә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 29 сентябрендәге
607 номерлы карары белән расланган
2 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмаларында туклану бәясе

<table>
<tr><td colspan="6">Шәһәр гомуми белем бирү оешмаларында</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Яшь төркеме</td><td colspan="2">Туклану бәясе, сум.</td><td colspan="2">Ата-аналар кертеме, сум.</td><td rowspan="2">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td>Бер тапкыр туклану</td><td>Ике тапкыр туклану</td><td>Бер тапкыр туклану</td><td>Ике тапкыр туклану</td></tr>
<tr><td>1-4 сыйныф</td><td>55,00</td><td>80,00</td><td>34,40</td><td>59,40</td><td>20,60</td></tr>
<tr><td>5-11 сыйныф*</td><td>60,00</td><td>90,00</td><td>39,40</td><td>69,40</td><td>20,60</td></tr>
<tr><td colspan="6">Авыл гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәһәр тибындагы Кама Аланы поселыгында</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Яшь төркеме</td><td colspan="2">Туклану бәясе, сум.</td><td colspan="2">Ата-аналар кертеме, сум.</td><td rowspan="2">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td>Бер тапкыр туклану</td><td>Ике тапкыр туклану</td><td>Бер тапкыр туклану</td><td>Ике тапкыр туклану</td></tr>
<tr><td>1-4 сыйныф</td><td>43,80</td><td>68,80</td><td>23,20</td><td>48,20</td><td>20,60</td></tr>
<tr><td>5-11 сыйныф</td><td>43,80</td><td>-</td><td>23,20</td><td>-</td><td>20,60</td></tr>
<tr><td colspan="6">ТР Түбән Кама муниципаль районы «БМББ №71» МБГББУда туклану бәясе</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Яшь төркеме</td><td colspan="2">Туклану бәясе, сум</td><td colspan="2">Ата-аналар кертеме, сум</td><td rowspan="2">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td colspan="2">Дүрт тапкыр туклану</td><td colspan="2">Дүрт тапкыр туклану</td></tr>
<tr><td>1-4 сыйныф</td><td colspan="2">132,00</td><td colspan="2">50,16</td><td>81,84</td></tr>
<tr><td colspan="6">Мәктәп-интернатларда яшәүче укучылар өчен туклану бәясе</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Яшь төркеме</td><td colspan="2">Туклану бәясе, сум</td><td colspan="2">Ата-аналар кертеме, сум</td><td rowspan="2">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td colspan="2">Биш тапкыр туклану</td><td colspan="2">Биш тапкыр туклану</td></tr>
<tr><td>1-11сыйныф</td><td colspan="2">134,35</td><td colspan="2">0</td><td>134,35</td></tr>
</table>

* Шәһәр гомуми белем бирү учреждениеләрендә өлкән сыйныфлар өчен ике тапкыр туклану (5-11 яшь) ата-аналар кертемнәре хисабына 30,00 сумлык өстәмә туклануны үз эченә ала.

Түбән Кама муниципаль районы гомуми  белем бирү оешмаларында түбәндәге категория балалар өчен туклану бәясе

| Ятим балалар һәм опекадагы балалар; инвалид балалар; Чернобыль АЭСдагы авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан гаилә балалары; Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан җан башына уртача керем түбәнрәк булган азкеремле, күпбалалы  һәм тулы булмаган гаилә балалары | | |
|---|---|---|
| Бер тапкыр туклану 1-4 сыйныф | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум. | Муниципаль  бюджет |
| шәһәр | 55,00 | 55,00 |
| авыл һәм<br>Кама Аланы штп | 43,80 | 43,80 |
| Ике тапкыр туклану  1-4 сыйныф | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум. | Муниципаль  бюджет |
| шәһәр | 80,00 | 80,00 |
| авыл һәм<br>Кама Аланы штп | 68,80 | 68,80 |
| Бер тапкыр туклану  5-11 сыйныф | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум. | Муниципаль  бюджет |
| шәһәр | 60,00 | 60,00 |
| авыл һәм<br>Кама Аланы штп | 43,80 | 43,80 |
| Күзләре начар күрүче балалар өчен компенсацияләү төрендәге 71 нче башлангыч мәктәп-балалар бакчасы | | |
| Яшь төркеме | Дүрт тапкыр туклану бәясе, сум. | Муниципаль  бюджет |
| 1-4 сыйныф | 132,00 | 132,00 |